**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 05.10.2020** **№ 769**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 773 нче номерлы «Биектау муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең, баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 августындагы 655 нче номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» Карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсенең «Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсенең «Мәгариф бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсенең «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен 2020 елның 1 октябреннән арттырырга.

2. Башкарма комитетның 2019 елның 29 маендагы 773 нче номерлы «Биектау муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең, баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсенең «Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсенең «Мәгариф бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУсенең «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» Нигезләмәсенең 3 пунктына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтерияләренең җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары»

таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 24411 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 22145 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 22145 |
| Бүлек начальнигы | 18231 | 18231 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 15759 | 15759 |
| Бухгалтер | 14420 | 14420 |

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисенә йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин